СОВЕТ
МЕНЗЕЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНЗӘЛӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

11.04.2016 ел г. Мензелинск № 7

# «2015 ЕЛ НӘТИҖӘЛӘРЕ БУЕНЧА МИНЗӘЛӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БЮДЖЕТЫНА САЛЫМНАР ҺӘМ БАШКА МӘҖБҮРИ ТҮЛӘҮЛӘР ТҮЛӘГӘННӘН СОҢ КАЛГАН МУНИЦИПАЛЬ УНИТАР ПРЕДПРИЯТИЕЛӘР ТАБЫШЫНЫҢ БЕР ӨЛЕШЕН КҮЧЕРҮ ТУРЫНДА»

«2016 елга Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы бюджеты турында» 2015 елның 17 декабрендәге N2 Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Советы карарының 5 статьясы нигезендә һәм Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы муниципаль унитар предприятиеләренең хуҗалык карамагындагы муниципаль мөлкәтнең керемен арттыру максатларында Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының 2015 елны табыш белән тәмамлаган муниципаль унитар предприятиеләре җитәкчеләренә:

2016 елның 1 июленә кадәр 2015 ел йомгаклары буенча алынган салымнарны түләгәннән соң калган керемнең 30 процентын Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы бюджетына күчерергә. Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы бюджетына түләүләр башкару өчен реквизитлар:

КБК - 99111107015050000120, исәп-хисап счеты - 40101810800000010001, алучылар банкы - ГРКЦ Татарстан Республикасы Милли банкы, Казан шәһәре - Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсе (Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Финанс-бюджет һәм җир-милек палатасы), банк БИК - 049205001, ИНН алучының - 1628006334, КПП алучының - 162801001, ОКТМО - 92640000;

2016 елның 1 августына кадәр Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Финанс-бюджет һәм җир-мөлкәт палатасына 2015 ел йомгаклары буенча табыштан Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы бюджетына күчерелгән акчаларның тиешле суммасын күчерү турында мәгълүмат, түләү документының күчермәсе белән, тапшырырга.

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Минзәлә муниципаль районы башлыгы урынбасары К.Р. Нәҗмиевкә һәм Совет план-бюджет-финанс комиссиясе рәисе Р.Ш.Газизяновка йөкләргә.

Совет рәисе А.Ф. Сәлахов